| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЫБНО-СЛОБОДСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛЫК БИСТӘСЕ МУНИЦИПАЛЬРАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

11.01.2023 Балык Бистәсе штп № 05пи

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 18.12.2023 №417 пи карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлегенә үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының $160^1$ статьясындагы $3^2$ пунктының өченче абзацы нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 18.12.2023 №417пи карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлегенә , "Балык Бистәсе муниципаль районы Финанс-бюджет палатасының 811" бүлеген түбәндәге эчтәлектәге юл белән тулыландырып үзгәрешләр кертергә:

| | | |
|---|---|---|
| 811 | 2 19 35118 05 0000 150 | Җирлекләрнең, муниципаль һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнары тарафыннан беренчел хәрби исәпкә алуны гамәлгә ашыруга субвенцияләрнең калган өлешләрен муниципаль районнар бюджетларыннан кире кайтару |
| 811 | 2 19 25576 05 0000 150 | Муниципаль районнар бюджетыннан авыл территорияләрен комплекслы үстерүне тәэмин итүгә субсидия калдыкларын кайтару |
| 811 | 2 18 35118 05 0000 150 | Җирлекләрнең, муниципаль һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнары тарафыннан беренчел хәрби исәпкә алуны гамәлгә ашыруга субвенцияләрнең калган өлешләрен җирлекләр бюджетларыннан кире кайтарудан муниципаль районнар бюджетлары керемнәре |

| | | |
|---|---|---|
| 811 | 2 18 25576 05 0000 150 | Муниципаль районнар бюджетларының җирлек бюджетларыннан авыл территорияләрен комплекслы үстерүне тәэмин итүгә субсидия калдыкларын кайтарудан кергән керемнәре |

2. Әлеге карар Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы бюджетын төзегәндә һәм үтәгәндә, 2024 елга бюджеттан башлап барлыкка килә торган хокук мөнәсәбәтләренә карата кулланыла.

3. Әлеге карарны http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында игълан итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче Д.А. Сатдинов